Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге составына керүче Олы Солтан авылы
торак пунктында үткән гражданнар җыенын нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2024 елның 22 ноябре № 1

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе нигезендә 2023 елның 23 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча үткәрелгән гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде: «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегендә тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына көндезге бүлекләргә йөреп укучы студентлардан, 1 группа инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту:

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган, җыенда катнашучылар исемлегенә 200 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 108 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 108 кеше тавыш бирде;

"ЮК" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге составына керүче Олы Солтан авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

Гражданнар җыенында куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегендә тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешеедән (уку йортларына көндезге бүлекләргә йөреп укучы студентлардан, 1 группа инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту ».

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфеев урамы, 12 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге составына керүче Олы Солтан авылы торак пунктында үткән гражданнар җыенын әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Б.М.Зәйнуллин